КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 13 октябрь г.Казань № 827

«Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасында балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне;

«Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проекты кысаларында коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

әлеге карар нигезендә «Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыруны оештырырга;

«Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыруга методик яктан ярдәм итүне тәэмин итәргә.

4. «Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында әлеге максат өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә 60 көн эчендә «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

7. Әлеге карар 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин